**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Сөйки поселогы Советы**
**КАРАРЫ**

**14 сентябрь 2018 ел** **№ 89**

**2017 елның 14 декабрендәге № 64 “Җир биләмәләреннән файдалану кагыйдәләрен раслау турында һәм Сөйки авыл җирлеге муниципаль берәмлек төзелешләре турында” гы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына үзгәрешләр кертү сәбәпле, гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге Советының карары 18.12.2013 ел №89 белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы " Сөйки авыл җирлеге» муниципаль берлегенең җирдән куллану һәм төзелешләр кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 статьяның унынчы абзацында «капиталь ремонт» сүзеннән соң “сүтергә” сүзен өстәргә:

1.2. 26 статьяда:

а) 1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Шәхси торак объектын, бакча йорты төзегәндә, реконструкцияләгәндә проект документларын әзерләүне гамәлгә ашыру таләп ителми. Төзүче үз инициативасы буенча шәхси торак төзелеше объектына, бакча йортына

карата проект документларын әзерләүне тәэмин итәргә хокуклы.»;

б) 8 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2) Җир кишәрлегенең планлаштыру схемасын җир кишәрлегенең планындагы информациягә туры китереп эшләнелгән;”;

в) 8 пунктның 7 пунктчасында «яки демонтаж» һәм “яисә демонтажны” сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 8 пунктның 10 пунктчасында «капиталь ремонт» сүзеннән соң “сүтергә” сүзен өстәргә.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан халыкка җиткерү мәгълүмат стендларына куярга:

- ТР Кама Тамагы районы Сөйки авылы, Кызыл Армия урамы, Авыл үзәге;

- ТР Кама Тамагы районы Сөйки авылы ,Колхоз урамы, 16а йорты, китапханә бинасы;

шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы

Кама Тамагы муниципаль районы

Сөйки авыл җирлеге Башлыгы,

Татарстан Республикасы

Кама Тамагы муниципаль районы

Сөйки авыл җирлеге Советы рәисе В.П. Никитин